РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

«31» октябрь, 2023 ел № 24

Ядегәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ядегәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Ядегәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2018 елның 07 ноябрендәге 30 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 9 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 8 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 7 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 16 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 3 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

б) 7 нче бүлектә:

5 нче пунктны «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

7 нче пунктны «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

10 нчы бүлектә:

7 нче пунктта «дөрес булмаган яки» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге 7.1 пункты белән тулыландырырга:

«7.1. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора»;

10 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алыштырырга;

б) 24 нче бүлектә:

түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункты белән тулыландырырга:

«1.1. Мунципаль хезмәткәр, «Муниципаль хезмәт турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгәне һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү ажардан бәйсез булган хәлләр тикшерүе тарафыннан «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылса икән ришвәтчелеккә каршы тору максатында җаваплылыктан азат ителә»;

3 пунктның 1 пунктчасын «яки «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан» дигән сүзләр белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы А.Н.Фәйзуллин